ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР № 1

Урыссу ш. т.п. 28.01 2022 ел

Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 29.11. 2021 ел, №14 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәсенә өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2020 елның 28 апрелендәге №5 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 29.11. 2021 ел, №14 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 8 статья өстәргә:

**«8. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1) Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында вәкаләтле органның законлы күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәү;

2) Вәкаләтле органга дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, иҗтимагый берләшмәләрдән, гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәҗбүри таләпләрне бозу һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы

барлыгы турында дәлилли торган гамәлләр (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар килү;

3) Җир эшләрен уздыруга ордер (рөхсәт) нигезендә эшләр башкару сроклары тәмамлану турында мәгълүмат алу, эшләрне аларны уздыруга ордер (рөхсәт) булмаган килеш башкару;

4) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләрен бозу билгеләрен ачыклау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының кеше хокуклары, законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе –
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы А. Ә. Шәфигуллин